# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советы (өченче чакырылыш)

Азнакай шәһәре № 119-29 «13» декабрь 2018ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 24 ноябрендәге 143-41 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында
(15.06.2015 №170-47, 21.10.2015 №10-2, 28.05.2018 №99-26,
12.11.2018 №114-28 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советы **карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 24 ноябрендәге 143-41 номерлы карарына (15.06.2015 №170-47, 21.10.2015 №10-2, 28.05.2018 №99-26, 12.11.2018 №114-28 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 3.1 һәм 3.2.пунктлар өстәргә:

«3.1. Физик затлар милкенә салым түләүдән азат итәргә:

1) 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарны;

2) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балигъ булмаган балаларын.

3.2. Салым ташламасы салым түләүче тарафыннан салым түләүченең милкендә булган һәм салым түләүче тарафыннан эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым объектына карата түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасын билгеләгәндә салым ташламасы салым ташламаларын куллану өчен нигезләр

санына карамастан салым түләүченең теләге буенча һәр төр салым салуның бер объектына карата бирелә.

Салым ташламасы, салым салуның мондый объектларында урнашкан гаражлар һәм машина-урыннардан тыш, Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларына карата бирелми.

Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым ташламаларын бирү турында гариза бирәләр, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасы бирелә торган салым түләүче тарафыннан салым органына тапшырыла торган салым салу объектлары турында хәбәрнамә үзенең теләге белән елның 1 ноябренә кадәр салым чоры булып торган салым органына тапшырыла, аннан башлап күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланыла.

Салым органына сайлап алынган салым салу объекты турында хәбәрнамә тапшырган салым чоры булып торган елның 1 ноябреннән соң салым салу объекты үзгәртелеп, күрсәтелгән салым чорында салым ташламасы тапшырыла торган төгәлләштерелгән белдерү кәгазе тапшырырга хокуклы түгел.

Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче сайлап алынган салым ташламасы салым салу объекты турында хәбәрнамәне тапшырмаган очракта салым ташламасы һәр төр салым салуның иң чик исәпләнгән суммасы белән бер объектына карата тапшырыла.»

1.2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының «Физик затларның милкенә салым турында»2014 елның 24 ноябрендәге 143-41 номерлы карарына үзгәреш кертү турында» 2018 елның 28 маендагы 99-26 номерлы карарында (15.06.2015 №170-47, 21.10.2015 №10-2) карарлар редакциясендә):

икенче пункттагы «һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар үз көченә “Маяк” газетасында рәсми бысылып чыккан көннән соң бер ай узгач үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан физик затлар милкенә салым исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны район «Маяк» газетасында бастырырга һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http//aznakayevo.tatarstan.ru.веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының бюджет, Финанслар, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин